



ФЕСТИВАЛЬ

# Укуда да, иҗатта да алдынгылар

**7 апрель көнне Казанның УНИКС концертлар залында «Язгы тамчы» республика фестиваленең гала-концерты узды. Фестиваль инде егерме беренче тапкыр Татарстан техникумнары һәм көллиятләренең иҗади яшьләрен җыя.**

Быел ул 85 һөнәри белем бирү учреждениеләрен, шул исәптән 13 мең укучы студентны үз эченә колачлады. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Минзәлә, Чистай, Тәтеш шәһәрләрендә фестивальнең сигез зона этабы узды.

2017 ел — Экология елы булуы уңаеннан, фестивальнең темасы да «Безнең дөнья. Минем Җирем» шигаре астында узды. Һәр чыгыш табигать темасына багышланган иде.

–Татарстанда яшьләр, студентлар, балалар өчен үткәрелгән фестивальләр һәрвакыт ташып торган энергия алып килә. Сезнең һәрберегез һичшиксез уңышка ирешәчәк. Ышанагыз, бу тормышта иҗат белән сәләт һәрвакыт кирәк булачак. Исегездә тотыгыз, сезнең идеяләрегез, эшегездән безнең республиканың, илнең киләчәге тора, – диде катнашучыларга Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева.

– Фестиваль һөнәри белем бирүче уку йортларында бик зур иҗат потенциалы яшеренгәнен тагын бер кат дәлилли. Сезнең сәләтегез, мөмкинлекләрегез яшәү дәверендә һәрвакыт кирәк булачак. Быел фестивальдә Казан укучылары гына түгел, республиканың барлык районнарыннан килгән студентлар катнашуы сөендерә, – диде Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры беренче урынбасары Андрей Поминов.

Бәйгенең фестиваль программасын әзерләү һәм театр юнәлеше буенча Гран-прины Казан педагогия көллияте алды. Музыкаль юнәлештә Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты, хореография буенча — Әлмәт политехник техникумы, оригиналь жанр буенча Алабуга политехник көллияте шулай ук Гран-при ияләре булдылар.

# «СӘЛӘТ» җәйге ялларга әзер

**Балаларның җәйге ялына алдан әзерләнеп кую хәерле. Әнә «Сәләт» лагере узган елның көзеннән үк әзерләнә башлаган инде.**

**Алисә САБИРОВА**

«Сәләт» республиканың барлык районнарына үтеп керде. Азнакай, Буа, Бөгелмә, Чаллы, Биектау районнарында быел да кызыклы сөрәннәр яңгыраячак. Алексеевск районындагы «Фәнсар» үзәгендә исә ел дәвамында дүртәр смена үткәрелә: «Сәләт-Осталар бистәсе», «Сәләт-Биләр каласы», «Сәләт-Санак», «Сәләт-Имәнкәй». Бу җәйдә «Сәләт» аланнарында 25 профильле сменалар эшләячәк, аларда 15 меңгә якын бала ял итәчәк.

Республикадан читтә яшәүче татар балалары да «сәлкеш» була ала. Самара өлкәсендә «Сәләт-Самара», Башкортстанның Туймазы районында «Сәләт-Кандракүл», Чувашия Республикасында «Сәләт-Батыр» аланнары эшли. Ә АКШ белән Канадада яшәүче татарлар «Сәләт-Монреаль» аланында татар теле белемнәрен шомартып, милли тәрбия ала.

Ел саен Биләр каласында шаулаган «Сәләт» форумы да быел, Татарстан Республикасы Президенты хәер-фатихасы белән, ике тапкыр узачак. Беренче смена дүртенче сәнәгать революциясе вакытында белем алуга юнәлтелгән. Бу форумда барлыгы 5000 кеше катнашыр дип көтелә. Икенче смена IT өлкәсе белән кызыксынучы 2500 кешене сыйдырачак. Форумның икенче өлеше мәгълүмати технологияләр, инновация, интеллектка багышланачак.

«Сәләт»тә ял итәргә теләүчеләр, инде февраль аеннан portfolio-selet.ru сайтында теркәлеп, гаризалар калдыра ала иде. Ә лагерьларның төрләре чиксез. «Сәләт-Раушан» аланын гына алыйк, бирегә иң сәләтле балалар гына сайлап алына. Башка аланнар белән чагыштырганда, татар телен белү мәҗбүри. Шулай ук төрле олимпиадаларда җиңү яулау да мәслихәт. Балалар ял итеп кенә калмый, ә иҗат, әдәбият, эшмәкәрлек нигезләренә дә төшенә. Хәтта төрле фәнни тәҗрибәләр дә ясый. «Сәләт-Осталар бистәсе» аланында сыерчык ояларын үз куллары белән ясап, орнитологларга кирәкле мәгълүмат туплаячаклар. Әйтик, ояга чип куеп, кошның кәнәнә ничә тапкыр өйгә кайтуын санап чыгаралар. Хәтта үзе җылына торган сыерчык оясы да ясыйлар икән.



Кече бизнес популярлашып киткән заманда, балаларның да эшмәкәрлелек серләренә төшенәсе килә. Шул максатлардан «Сәләт-Эшмәкәр» аланы булдырылган. «Сәләт» фонды башкарма директоры Тимур Сөләйманов сүзләренчә, әлеге алан балаларны эшлеклелеккә, финанслау нигезенә төшенергә, идеяне тормышка ашырырга өйрәтә. Соңгы көндә балалар әти-әнисен ял дәверендә ирешкән уңышлары белән таныштырып, ярминкә оештыра.

«Сәләт» яшьләр үзәге директоры Айгөл Габдрахманова сүзләренчә, «Сәләт» ул – өч телле мохит.

– «Сәләт» – акыл, рух, тел берлеге. Бездә чараларның 50 проценттан артыгы татар телендә бара. Шуңа да тел белмәгән кешегә ияләшеп китү авыррак булырга мөмкин. Ләкин татар телен белү төп таләп түгел. Иң мөһиме – балада тел өйрәнергә теләк булсын. Минемчә, бүген Татарстанда яшәп тә татар телен өйрәнү мөмкинлеген кулдан ычкындыру – ахмаклык. Татар теле – теләсә кайсы төрек теленә ачкыч бит ул. Бездә татар телен үз теле кебек өйрәнгән кешеләр бик күп. Алена Быкованы гына алыйк, ул – рус кызы. «Сәләт»нең башка балалары белән бергә, ул Монреальгә барачак, – диде Айгөл Габдрахманова.

«Сәләт» аланнарына 5-11нче сыйныф балаларын кабул итәләр.